**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 7 маендагы 1412 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4277 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу белән идарә итү регламенты турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы федераль закон нормаларын нәтиҗәле үтәү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4277 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу белән идарә итү регламенты турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 27 апрелендәге 1534 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 3813 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге 6550 номерлы, 2019 елның 15 маендагы 1834 номерлы, 2019 елның 26 июнендәге 2301 номерлы, 2019 елның 23 июлендәге 2690 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 3998 номерлы, 2020 елның 7 сентябрендәге 2460 номерлы, 2021 елның 8 апрелендәге 826 номерлы, 2021 елның 25 июнендәге 1556 номерлы, 2021 елның 28 декабрендәге 3495 номерлы, 2022 елның 28 февралендәге 577 номерлы, 2022 елның 18 апрелендәге 1152 номерлы, 2022 елның 25 августындагы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4277 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 7 маендагы
1412 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу белән идарә итү регламенты**

Казан

Документ создан в электронной форме. № 71580-Инф от 20.06.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 3 из 45. Страница создана: 20.06.2025 15:09
ЕМСЭД

# ЭЧТӘЛЕК

Глоссарий ........ 3
I. Гомуми нигезләмәләр ........ 6
1.1. Регламентның максатлары, билгеләнеше һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибе ........ 6
1.2. Норматив сылтамалар. ........ 6
II. Процессларның гомуми тасвирламасы ........ 7
2.1. Процессларның максаты һәм бурычлары ........ 7
2.2. Процессларның составы ........ 8
2.3. Тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү ысуллары ........ 8
2.4. Мәгълүмати яктан тәэмин итү ........ 8
III. Төп рольләр ........ 9
3.1. Катнашучылар составы ........ 9
IV. Сатып алуларны планлаштыру ........ 11
V. Сатып алуларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру ........ 11
5.1. Сатып алуны уздыруга гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документларны әзерләү. ........ 11
5.2. Сатып алу турында мәгълүматлар урнаштыру ........ 16
5.3. Конкурентлы процедуралар үткәрү ........ 17
5.4. Контракт төзү ........ 18
VI. Сатып алуларны әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту ........ 18

Документ создан в электронной форме. № 71580-Инф от 20.06.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 4 из 45. Страница создана: 20.06.2025 15:09
ЕМСЭД

# Глоссарий

## Терминнар

Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

| Термин | Билгеләмә |
|---|---|
| Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы | 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы федераль законның (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) 4 статьясы нигезендә төзелә торган сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы |
| Заказ бирүче | Казан шәһәренең җирле үзидарә органы, муниципаль бюджет учреждениесе, муниципаль казна учреждениесе, муниципаль автоном учреждениесе |
| Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасының ябык өлеше | Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында әлеге системада теркәлгән оешмалар өчен функцияләр һәм мәгълүматлар җыелмасын билгели торган һәм электрон имза сертификатын кулланып файдаланырга мөмкин булган эш өлкәсе |
| Мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләре өлкәсендә товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу | МТ-сатып алулар исемлегенә кертелгән сатып алу (11 номерлы кушымта) |
| Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу | Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу максатыннан заказ бирүче тарафыннан башкарыла торган һәм Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән гамәлләр җыелмасы. Сатып алу тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдән башлана һәм контракт яклары тарафыннан йөкләмәләрне үтәү белән тәмамлана. Россия Федерациясе законнары нигезендә сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамә урнаштыру яки тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә катнашырга чакыру җибәрү каралмаса, сатып алу контракт төзүдән башлана һәм контракт яклары тарафыннан йөкләмәләрне үтәү белән тәмамлана |
| Сатып алу үткәрүгә гариза, Гариза | Заказ бирүченең сатып алуны гамәлгә ашыру эшчәнлеген башлап җибәрү максатыннан сатып алу предметы, бәясе һәм аны үткәрү шартлары турында кирәкле һәм җитәрлек барлык мәгълүматны үз эченә алган документы |
| Сатып алулар өлкәсендә контроль орган | 44-ФЗ номерлы федераль законның 99 статьясындагы 3 өлеше белән каралган сатып алулар өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы |
| Контракт бәясенең максималь күрсәткече | Китерелә торган товарлар санын, башкарылырга тиешле эшләр, хезмәт күрсәтүләр күләмен билгеләү мөмкин булмаган очракта контрактның башлангыч (максималь) бәясе урынына билгеләнә торган күрсәткече |

| Термин | Билгеләмә |
|---|---|
| Финанс контроле органы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге финанс органы яки җирле администрация белән килешү нигезендә 44-ФЗ номерлы федераль законның 99 статьясындагы 5 өлеше белән каралган контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлешенә казна хезмәте күрсәтү буенча хокук куллану функцияләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы |
| Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасының ачык өлеше | Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алулар һәм 44-ФЗ номерлы федераль закон һәм 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында»гы федераль закон нигезендә эшчәнлек алып бара торган оешмалар турында һәркем файдалана алырлык бастырылган мәгълүматны үз эченә алган эш өлкәсе |
| Сатып алуларның план-графигы | Заказ бирүче функцияләрен гамәлгә ашыру өчен һәм Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү кысаларында башка максатларга ирешү өчен кирәкле товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу исемлеген үз эченә алган, бюджет турында карарның гамәлдә булу вакытына туры килүче финанс чорына формалаштырыла торган заказ бирүче документы |
| Тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү | Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамә урнаштырудан башлап контракт төзү белән тәмамлауга кадәр 44-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә заказ бирүчеләр тарафыннан башкарыла торган гамәлләр җыелмасы |
| Тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) | 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә контракт төзелгән сатып алуда катнашучы |
| Вәкаләтле учреждение | 44-ФЗ номерлы федераль законның 26 статьясы нигезендә заказ бирүчеләрнең ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү буенча вәкаләтләр йөкләнгән Казан шәһәре муниципаль казна учреждениесе |
| Мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләре өлкәсендә эксперт | МТ-сатып алулар исемлеге (11 номерлы кушымта) нигезендә МТ-сатып алулар үткәрүгә гаризаларны килештерү функцияләре йөкләнгән «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәре |
| Электрон мәйданчык | Электрон сәүдәнең гомумроссия системасы, Интернет челтәрендә www.etp.zakazrf.ru адресы буенча урнашкан электрон сәүдә мәйданчыгы – электрон формада конкурентлы процедуралар үткәрү, шулай ук 44-ФЗ номерлы федераль законының 93 статьясындагы 12 өлеше белән каралган суммага бердәнбер тәэмин итүчедән электрон формада товар сатып алу урыны |

**Кыскартылмалар**

Әлеге регламентта түбәндәге кыскартылмалар кулланыла:

| Кыскартылма | Билгеләмә |
|---|---|
| Дирекция | «Казан шәһәренең конкурентлык сәясәте һәм сатып алулар дирекциясе» муниципаль казна учреждениесе |
| Бердәм мәгълүмат системасы | Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы |
| 44-ФЗ номерлы федераль закон | 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы федераль закон |
| Бердәм мәгълүмат системасының ябык өлеше | Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасының ябык өлеше |
| Сатып алу | Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу |
| МТ-сатып алу | Мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләре өлкәсендә товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу |
| МТ-эксперт | Мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләре өлкәсендә эксперт |
| Бердәм мәгълүмат системасының ачык өлеше | Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасының ачык өлеше |
| Электрон документлар әйләнеше системасы | Электрон документлар әйләнешенең ведомствоара системасы |
| Электрон цифрлы имза | Көчәйтелгән квалификацияле электрон имза |
| Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия | Конкурентлы процедуралар үткәргәндә, тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү буенча функцияләрне башкара торган бердәм комиссия |
| Электрон кибет | Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасы |

Документ создан в электронной форме. № 71580-Инф от 20.06.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 7 из 45. Страница создана: 20.06.2025 15:09
ЕМСЭД

# I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентның максатлары, билгеләнеше һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибе.

1.1.1. Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу белән идарә итүнең әлеге регламенты (алга таба – Регламент) 44-ФЗ номерлы федераль закон, әлеге закон нигезендә һәм аны үстерү өчен кабул ителгән норматив хокукый актлар йогынтысы кысаларында муниципаль сатып алуларны әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда Казан шәһәре җирле үзидарә органнары, муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм муниципаль автоном учреждениеләре структур бүлекчәләренең һәм вазифаи затларының эш тәртибен билгели.

1.1.2. Регламентның максаты – сатып алу эшчәнлеген оештырганда Казан шәһәре муниципаль учреждениеләренең һәм җирле үзидарә органнарының бердәм кагыйдәләрен һәм эш тәртибен формалаштыру.

1.1.3. Регламент Казан шәһәре Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) карары белән раслана һәм расланган көннән башлап Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу белән идарә итү процессларында (алга таба – Процесслар) катнаша торган Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының, муниципаль казна учреждениеләренең, муниципаль бюджет учреждениеләренең, муниципаль автоном учреждениеләренең барлык структур бүлекчәләре һәм вазифаи затлары тарафыннан аны үтәү мәҗбүри булып тора.

1.1.4. Башкарма комитетның теләсә кайсы структур бүлекчәсе, муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Регламентка үзгәрешләр кертү инициаторы булып тора ала. Үзгәрешләр кертү зарурлыгы турындагы мөрәҗәгатьләр Дирекциягә җибәрелә. Кертелә торган үзгәрешләр уңаеннан кызыксынучы яклар белән фикер алышу нәтиҗәләре буенча, алар кабул ителгән очракта, Дирекция Регламентка үзгәрешләр кертү турында Башкарма комитет карары проектын әзерли һәм аны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

1.1.5. Регламентка кертелә торган барлык үзгәрешләр Башкарма комитет карары белән раслана.

1.1.6. Процессларны оештыру өчен җаваплы һәм Процессларны үзгәртү турында карарлар кабул итү вәкаләтенә ия зат – Дирекция директоры.

1.1.7. Регламент таләпләре үтәлешен оператив контрольдә тоту өчен Дирекция директоры урынбасарлары җаваплы.

1.2. Норматив сылтамалар.

Регламент түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә эшләнгән:

- 44-ФЗ номерлы федераль закон;

- 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы «Конкуренцияне яклау турында»гы федераль закон;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 4 сентябрендәге 775 номерлы «Бәя арттырган очракта контрактта тәэмин итүченең (подрядчының, башкаручының) заказ бирүчегә өстәмә мәгълүмат бирү бурычы билгеләнә торган товар, эш, хезмәт

күрсәтүләр сатып алганда контрактның башлангыч (максималь) бәясе күләмен билгеләү турында»гы карары;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 июнендәге 1078 номерлы «Намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрын алып бару тәртибе турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм кайбер актларындагы аерым нигезләмәләрен гамәлдән чыккан дип тану турында»гы карары;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 19 декабрендәге 1186 номерлы «Контракт төзегән якларга бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу сәбәпле контрактны шартларын үзгәртмичә үтәү мөмкин булмаган очракта, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы һәм җирле администрация карары нигезендә яклар килешүе буенча контрактның мөһим шартлары үзгәртелергә мөмкин булган яки аны арттырганда үзгәртелергә мөмкин булган контракт бәясе күләмен, контракт бәясенец чик күләмен билгеләү турында»гы карары;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 сентябрендәге 1279 номерлы «Сатып алуларның план-графиклары турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында»гы карары;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 31 декабрендәге 2604 номерлы «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуда катнашуга гаризаларны бәяләү, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 20 декабрендәге 2369 номерлы карарының 4 пунктына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм кайбер актларының аерым нигезләмәләрен гамәлдән чыккан дип тану турында»гы карары;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 13 августындагы 585 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасы турында»гы карары.

## II. Процессларның гомуми тасвирламасы

2.1. Процессларның максаты һәм бурычлары.

2.1.1. Процессларның төп максаты - гамәлдәге законнар нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын тоту нәтиҗәлелегенә карата куелган таләпләр нигезендә Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын гамәлгә ашыруны үз вакытында һәм сыйфатлы итеп тәэмин итү.

2.1.2. Процессларда түбәндәге төп бурычлар хәл ителә:

- Казан шәһәре ихтыяҗларын тәэмин итү өчен кирәкле сатып алулар составын, чыгымнарны планлаштыру;

- сатып алуларны башлап җибәрү һәм китерелә торган товарларга, башкарыла торган эшләргә һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә карата таләпләрне җентекләп формалаштыру;

- тиешле нәтиҗәләр алу һәм план-графикларны вакытында үтәү өчен конкурентлы процедуралар үткәрүне һәм товарлар китерүне, эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне оештыру;

- план-графикларны, контрактларны гамәлгә ашыруны даими мониторинглау, тайпылышларны ачыклау һәм аларны үз вакытында бетерү өчен карарлар кабул итүне тәэмин итү;

- сатып алуларның йомгаклау нәтиҗәләренең заказ бирүчеләр таләпләренә туры килүен тәэмин итү.

2.2. Процессларның составы.

Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗлары өчен сатып алулар белән идарә итү түбәндәге процессларны үз эченә ала:

1) сатып алуларны планлаштыру:

- сатып алуларның план-графигын формалаштыру һәм аңа үзгәрешләр кертү;

2) сатып алуларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру:

- сатып алу уздыруга гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны әзерләү;

- сатып алу турында мәгълүмат урнаштыру;

- конкурентлы процедуралар үткәрү;

- контракт төзү;

- контрактны үтәү;

- контрактка үзгәрешләр кертү;

- контрактны өзү;

3) сатып алуларны әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту.

2.3. Тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү ысуллары.

2.3.1. Заказ бирүчеләр тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүнең конкурентлы ысулларын куллана яки бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) сатып алуны гамәлгә ашыра. Тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү ысулын сайлау 44-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә башкарыла. Казан шәһәре муниципаль заказ бирүчеләре өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүнең конкурентлы ысуллары түбәндәгеләр:

- электрон формада ачык конкурс (алга таба – электрон конкурс);

- электрон формада ачык аукцион (алга таба – электрон аукцион);

- электрон формада котировкалар соратып алу.

2.3.2. 44-ФЗ номерлы федераль законның 93 статьясындагы 12 өлеше белән каралган суммага бердәнбер тәэмин итүчедән товар сатып алулар электрон формада үткәрелергә мөмкин.

2.4. Мәгълүмати яктан тәэмин итү.

Процессларны мәгълүмати яктан тәэмин итү максатыннан түбәндәге мәгълүмат системалары кулланыла:

1) Бердәм мәгълүмат системасы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- сатып алуларның план-графикларын формалаштыру һәм урнаштыру;

- финанс контроле органы тарафыннан контроль узу нәтиҗәләрен дә кертеп, 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә сатып алулар турында мәгълүмат урнаштыру;

2) Электрон кибет түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- конкурентлы сатып алулар уздыруга гаризалар буенча мәгълүмат кертү, вәкаләтле учреждение тарафыннан аларны анализлау, шулай ук финанс контроле органы белән килештерү;

- лотлар, сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәләр формалаштыру һәм аларны Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру өчен җибәрү;

- контрактлар, аларны үтәү, үзгәртү һәм өзү буенча мәгълүмат кертү;

3) конкурентлы процедураларны һәм бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) электрон формада сатып алуны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган электрон мәйданчык.

## III. Төп рольләр

3.1. Катнашучылар составы.

Процессларда катнашучылар составына түбәндәгеләр керә:

| № т/б | Роль | Төп функцияләр һәм вәкаләтләр |
|---|---|---|
| 1 | Заказ бирүче | - сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау, аларны финанс контроле органына контрольгә җибәрү һәм Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру;<br>- конкурентлы сатып алулар буенча сатып алу үткәрүгә гаризалар һәм аңа теркәп бирелә торган документларны формалаштыру, шул исәптән контрактның башлангыч (максималь) бәясен, берәмлекнең башлангыч бәясен нигезләү;<br>- вәкаләтле учреждение тарафыннан әзерләнгән хәбәрнамә проектын раслау;<br>- 44-ФЗ номерлы федераль законның 93 статьясындагы 12 өлеше белән каралган суммага электрон формада бердәнбер тәэмин итүчедән товар сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамә формалаштыру һәм аны Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру;<br>- сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәгә үзгәрешләр кертү өчен хат формалаштыру;<br>- тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүне гамәлдән чыгару турында хат формалаштыру;<br>- сатып алу турында хәбәрнамә нигезләмәләренә аңлатмалар формалаштыру;<br>- сатып алу объекты турында мәгълүмат җитәрлек булмаганда, Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия өчен аңлатма характерында хатлар формалаштыру;<br>- 44-ФЗ номерлы федераль законның 93 статьясындагы 12 өлеше нигезендә бердәнбер тәэмин итүчедән электрон формада сатып алган очракта, тәэмин итүчене билгеләү нәтиҗәләре беркетмәсен төзү һәм аны электрон мәйданчык операторына җибәрү; |

Документ создан в электронной форме. № 71580-Инф от 20.06.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 11 из 45. Страница создана: 20.06.2025 15:09
ЕМСЭД

| № т/б | Роль | Төп функцияләр һәм вәкаләтләр |
|---|---|---|
| | | - контракт проектын формалаштыру һәм аны имзалау, каршылыклар беркетмәсе искәрмәләрен исәпкә алудан баш тарту сәбәпләрен үз эченә алган документ төзү, аларны Бердәм мәгълүмат системасында һәм электрон мәйданчыкта урнаштыру;<br>- сатып алуда катнашучыны тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә катнашудан читләштерү;<br>- контракт төзүдән баш тарту турында беркетмә формалаштыру, аны Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру;<br>- 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә сатып алуларда катнашучыны (шул исәптән җиңүчене) баш тарткан дип тану турында карар кабул итү;<br>- 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә сатып алуларда катнашучыны баш тарткан дип тану турында беркетмә төзү, аны Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру;<br>- контракт үтәүне тәэмин итүне раслый торган документларны тикшерү. Акча күчерелгән очракта – аларның вәкаләтле учреждение счетына кучүен тикшерү;<br>- контракт төзү;<br>- 44-ФЗ номерлы федераль законның 93 статьясы белән каралган очракларда сатып алулар өлкәсендә контроль орган белән контракт төзүне килештерү;<br>- контракт төзү, аны үтәү, үзгәртү һәм өзү турында белешмәләрне Электрон кибеткә, Бердәм мәгълүмат системасына кертү, финанс контроле органына контрольгә җибәрү һәм Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру;<br>- кече эшмәкәрлек субъектларыннан, социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалардан сатып алулар күләме турында хисап формалаштыру;<br>- сатып алуларның план-графиклары үтәлешен мониторинглау һәм контрольдә тоту;<br>- контракт үтәлешен контрольдә тоту һәм товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен кабул итү;<br>- контракт төзүдән читләшкән сатып алуда катнашучылар, суд карары нигезендә яки контракт шартларын җитди бозу белән бәйле рәвештә заказ бирүченең контрактны үтәүдән берьяклы баш тартуы нәтиҗәсендә контрактлар өзелгән тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) турында, намуссыз тәэмин итүчеләр реестрына кертү өчен, мәгълүмат тапшыру |
| 2 | Вәкаләтле учреждение | - Сатып алулар үткәрүгә гаризаларның һәм теркәлә торган документларның, контрактның башлангыч (максималь) бәясе/товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлегенең башлангыч бәясе нигезләмәсен дә кертеп, конкурентлы сатып алулар турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвенә анализ;<br>- Электрон кибеттә конкурентлы процедуралар буенча сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәләр формалаштыру, аларны финанс контроле органына килештерүгә җибәрү һәм Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру;<br>- Электрон кибеттә, Бердәм мәгълүмат системасында сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәгә үзгәрешләрне, сатып алу турында хәбәрнамә нигезләмәләренә үзгәрешләрне формалаштыру, аларны |

| № т/б | Роль | Төп функцияләр һәм вәкаләтләр |
|---|---|---|
| | | финанс контроле органына контрольгә җибәрү һәм Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру;<br>- Бердәм мәгълүмат системасында сатып алу турында хәбәрнамә нигезләмәләренең аңлатмаларын урнаштыру;<br>- Бердәм мәгълүмат системасында сатып алуны гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә урнаштыру;<br>- сатып алуларны әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту;<br>- электрон конкурс, электрон аукцион, электрон формада котировкалар соратып алу уздырганда җиңүчене ачыклау, тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү буенча функцияләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 25 декабрендәге 10204 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру турында»гы карары нигезендә Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия эшенең беркетмәләрен формалаштыру, имзалау һәм электрон мәйданчык операторына җибәрү |
| 3 | МТ-эксперт | МТ-сатып алулар үткәрүгә гаризаларны килештерү |
| 4 | Электрон мәйданчык операторы | 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә билгеләнә |
| 5 | Сатып алуда катнашучы | 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә билгеләнә |
| 6 | Сатып алулар өлкәсендә контроль орган | 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә билгеләнә |
| 7 | Финанс контроле органы | 44-ФЗ номерлы федераль закон һәм эчке регламентлар нигезендә билгеләнә |

## IV. Сатып алуларны планлаштыру

Сатып алуларның план-графигын формалаштыру һәм аңа үзгәрешләр кертү 44-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

## V. Сатып алуларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру

5.1. Сатып алуны уздыруга гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документларны әзерләү.

5.1.1. Сатып алуны уздыруга гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар электрон форматта әзерләнә.

5.1.2. Бердәм мәгълүмат системасында сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамә урнаштыру планлаштырыла торган көнгә кадәр 10 эш көненнән дә (капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкаруга сатып алу уздыру очрагында – 13 эш

көненнән, уртак аукцион яки конкурс үткәрелгән очракта – 30 календарь көннән) соңга калмыйча:

5.1.2.1. заказ бирүче сатып алу үткәрү турында гариза белән бәйле мәгълүматны, шул исәптән, сатып алуларны 44-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы нигезендә гамәлгә ашырганда, милли режим бирү турында белешмәләрне, Электрон кибеткә кертә, кушымта итеп бирелә торган документларны архивлаштырылган рәвештә терки, гаризаны электрон цифрлы имза белән имзалый, шулай ук беркетелгән файл исемнәренең дөреслеген, гариза эчтәлегенә туры килү-килмәвен тикшерә һәм анализ ясау өчен вәкаләтле учреждениегә юллый:

- Регламентка 1 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча сатып алуны үткәрүгә электрон документ рәвешендә гаризаны;

- сатып алуны үткәрү турында гаризага 1 номерлы кушымтаны – 44-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә сатып алу объекты турында мәгълүматны (товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен тәкъдим ителгән төрле формалар Регламентка 8 – 10 номерлы кушымталарда китерелгән). Сатып алу объекты турында мәгълүматка кушымталар булса, аларга тәртип номеры бирелә (мәсәлән: 1.1 номерлы кушымта «Сметалар»; 1.2 номерлы кушымта «Графиклар»; 1.3 номерлы кушымта «Исемлек» һ.б.);

- капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү эшләрен башкаруны сатып алу гамәлгә ашырылган очракта – Регламентның 9 номерлы кушымтасында китерелгән форма буенча сатып алу объекты турында мәгълүмат. Ул шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар белән билгеләнгән тәртиптә расланган проект документларын яки типлаштырылган проект документларын яисә капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлауга сметаны (күрсәтелгән законнар нигезендә мондый проект документларын һәм смета әзерләү таләп ителмәгән очрактан, шулай ук 44-ФЗ номерлы федераль законның 34 статьясындагы 16 һәм 16.1 өлешләре нигезендә контракт предметы булып шул исәптән капиталь төзелеш объектын проектлау торган сатып алуны гамәлгә ашыру очракларыннан тыш) үз эченә ала;

- сатып алуны үткәрү турында гаризага 2 номерлы кушымтаны – Регламентка 2 – 7 номерлы кушымталарда китерелгән формалар буенча контрактның башлангыч (максималь) бәясен/контрактның максималь бәя күрсәткечен нигезләүне (Word яки Excel форматында) һәм контрактның башлангыч (максималь) бәясен/контрактның максималь бәя күрсәткечен билгеләүнең гаризада сайлап алынган алым(-нар)ына бәйле рәвештә раслый торган документларны (коммерция тәкъдимнәре һ.б.). Контрактның башлангыч (максималь) бәясен/контрактның максималь бәя күрсәткечен билгеләүнең берничә алымын сайлап алган очракта, күрсәтелгән һәм башка формаларны берләштерү рөхсәт ителә;

- сатып алуны үткәрү турында гаризага 3 номерлы кушымтаны – контракт проектын;

- атып алуны үткәрү турында гаризага 4 номерлы кушымтаны – катнашуга гаризаларны карап тикшерү һәм бәяләү тәртибен (электрон конкурслар үткәрелгән очракта);

- сатып алуны МТ-эксперт белән килештерүне раслый торган документны (МТ-сатып алу очрагында) (МТ-сатып алуларга караган сатып алулар исемлеге

Регламентка 11 номерлы кушымтада китерелгән). МТ-сатып алуны үткәрүгә гаризаны килештерү заказ бирүче тарафыннан контракт проекты, сатып алу объекты турында мәгълүмат, коммерция белән бәйле кимендә өч тәкъдим [түләүгә счетлар, тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) сайтларыннан бәяләр белән скриншотлар] тапшырылган очракта гына МТ-эксперт тарафыннан башкарыла.

Хәбәрнамә проекты ышанычнамә буенча (Регламентка 12 номерлы кушымтада күрсәтелгән форма һәм рекомендацияләр нигезендә) эш йөртүче зат яки, җитәкчедән тыш, вәкаләт бирелгән зат тарафыннан имзаланган очракта, гариза составына өстәмә рәвештә ышанычнамә теркәлә.

Заказ бирүчеләр сатып алуны гамәлгә ашыруның максатчанлыгы, аның бюджет сметасына яки бюджет учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планына туры килүе, гариза составындагы документларның 44-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә туры килүе өчен законнар нигезендә җавап бирә;

5.1.2.2. бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) МТ-сатып алу очрагында, заказ бирүче сатып алуны үткәрүгә ирекле формада гариза яза һәм аны МТ-экспертка килештерүгә юллый. Гаризага түбәндәге документлар теркәп бирелергә тиеш:

- сатып алу объекты турында мәгълүматны үз эченә алган кушымта белән контракт проекты;

- гаризада контрактның башлангыч (максималь) бәясен/контрактның максималь бәя күрсәткечен билгеләүнең сайлап алынган алым(-нар)ына бәйле рәвештә контракт бәясен, товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлекләренең башлангыч бәясен нигезләүне раслый торган документлар [коммерция тәкъдимнәре, түләүгә счетлар, тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) сайтларыннан бәяләр белән скриншотлар].

5.1.3. Бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) МТ-сатып алу очрагында, МТ-эксперт, гариза кергән көннән соң килә торган эш көненнән башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча, МТ-сатып алу үткәрү турында гаризаны карап тикшерә.

5.1.4. МТ-сатып алуны үткәрү өчен гаризага карата искәрмәләр булган очракта, МТ-эксперт МТ-сатып алуны үткәрү турында гаризага искәрмәне Регламентның 5.1.3 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә заказ бирүчегә юллый.

5.1.5. МТ-эксперттан искәрмәләрне алган көннән соң килә торган эш көненнән башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча, заказ бирүче кимчелекләрне бетерә һәм сатып алуны үткәрү турында төзәтелгән гаризаны МТ-экспертка җибәрә.

5.1.6. Төзәтмәләр кертелгән гариза кергән көннән соң килә торган эш көненнән башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча, МТ-эксперт МТ-сатып алу үткәрү турында төзәтелгән гаризаны кабат карап тикшерә. Гариза буенча искәрмәләр һәм сораулар булмаган очракта, МТ-эксперт МТ-сатып алу үткәрү турында гаризаны килештерә.

5.1.7. Конкурентлы процедуралар буенча сатып алу үткәрү турында гариза кергән көннән соң килә торган эш көненнән башлап өч эш көненнән (капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкаруга сатып алу уздыру очрагында – биш эш көненнән) дә соң калмыйча, вәкаләтле учреждение сатып алу үткәрү турында гаризаны түбәндәге критерийлар буенча карап тикшерә:

- сатып алуны үткәрү турында гаризада күрсәтелгән контрактның башлангыч (максималь) бәясенең базар бәяләре дәрәҗәсенә тәңгәл килүе;

- Россия Федерациясе законнары нормаларына, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив актларына тәңгәл килүе, шул исәптән сатып алу процедуралары предметының нигезләнгән булуы, товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә контрактның башлангыч (максималь) бәясе/товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлегенең башлангыч бәясен нигезләү һәм билгеләүне сайлау.

5.1.8. Сатып алуны үткәрү турында гаризага карата искәрмәләр булган очракта, вәкаләтле учреждение Электрон кибеттә сатып алуны үткәрү турында гаризага карата искәрмәләр исемлеген формалаштыра һәм аны Регламентның 5.1.7 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә заказ бирүчегә юллый.5.1.7

5.1.9. Сатып алу үткәрү турында гаризага карата аныклык кертергә кирәкле сораулар булган очракта, вәкаләтле учреждение Регламентның 5.1.7 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә сорауларга тиз арада аныклык кертә.

5.1.10. Вәкаләтле учреждениедән искәрмәләр алынган көннән соң килә торган эш көненнән башлап өч эш көненнән (капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкаруга сатып алу уздыру очрагында – биш эш көненнән) дә соң калмыйча, заказ бирүче кимчелекләрне бетерә һәм төзәтмәләр кертелгән сатып алуны уздыру турында гаризаны Электрон кибет аша вәкаләтле учреждениегә юллый. Әмма әлеге гаризаны юк итәргә (гамәлдән чыгарырга) һәм шул ук сатып алуны үткәрү турында яңа гариза формалаштырырга рөхсәт ителми.

5.1.11. Төзәтелгән гариза кергән көннән соң килә торган эш көненнән башлап өч эш көненнән (капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкаруга сатып алу уздыру очрагында – биш эш көненнән) дә соңга калмыйча, вәкаләтле учреждение төзәтмәләр кертелгән сатып алу үткәрү турында гаризаны кабат карап тикшерә. Заказ бирүче бер үк искәрмәне ике тапкыр төзәтмәгән очракта, вәкаләтле учреждение гаризаны карап тикшермичә кире кайтарырга һәм заказ бирүче җитәкчесенә, Башкарма комитет Җитәкчесенең әлеге мәсьәлә өчен җаваплы урынбасарына төзәтелмәгән искәрмәләр турында язмача хәбәр итәргә хокуклы. Искәрмәләр ике тапкыр төзәтелмәгән гаризаны Вәкаләтле учреждение тарафыннан карап тикшерүне яңарту өчен заказ бирүче җитәкчесе яки ышанычнамә буенча (12 номерлы кушымта) эш йөртүче вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган гаризаны карап тикшерүне яңарту турында язма мөрәҗәгатьне вәкаләтле учреждениегә җибәрү зарур. Вәкаләтле учреждениегә җибәрер алдыннан конкурентлы процедуралар буенча сатып алулар уздыру турында гаризалар Электрон кибеттә заказ бирүче җитәкчесе яки ышанычнамә (Регламентка 12 номерлы кушымтада күрсәтелгән форма һәм тәкъдимнәр нигезендә) нигезендә эш йөртүче һәм имзалау вәкаләтенә ия зат тарафыннан электрон цифрлы имза белән имзалана.

5.1.12. Электрон кибеттә гаризаны имзалау Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсенең таныклаучы үзәге тарафыннан бирелгән электрон имзаны тикшерү ачкычларының квалификацияле сертификатларын һәм электрон имза чараларын кулланып башкарыла.

5.1.13. Имзалаганнан соң вәкаләтле учреждение гаризаны финанс контроле органына җибәрә.

5.1.14. Өч эш көне (капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкаруга сатып алу уздыру очрагында – җиде эш көне) узганнан соң, финанс контроле органы тарафыннан сатып алу турындагы гаризаны килештерү статусы буенча мәгълүмат булмаган очракта, заказ бирүче финанс контроле органыннан планлаштырыла торган сатып алуга карата кабул ителгән карар турында мәгълүматны аныклый.

5.1.15. Финанс контроле органы тарафыннан сатып алу турында гариза кире кагылган очракта, заказ бирүче, кабат анализ ясау максатыннан, сатып алу үткәрү турында гаризаның төзәтелгән вариантын вәкаләтле органга җибәрә.

5.1.16. Уртак сатулар үткәрү турында гаризага анализ ясау.

5.1.16.1. Уртак электрон конкурс яки электрон аукцион үткәрелгән очракта, заказ бирүчеләрнең берсе Электрон кибеттә җыелма гариза формалаштыра, уртак сатулар үткәрү турында килешүне беркетә һәм, анализ ясау максатыннан, җыелма гаризаны Регламентның 5.1.2 пункты белән билгеләнгән вакыт эчендә вәкаләтле учреждениегә юллый.

5.1.16.2. Уртак сатулар үткәрү турында җыелма гаризага анализ ясау нәтиҗәләре буенча ачыкланган кимчелекләрне биргән көннән соң килә торган эш көненнән башлап өч эш көненнән (капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкаруга сатып алу уздыру очрагында – биш эш көненнән) дә соңга калмыйча, башка заказ бирүчеләр Электрон кибеттәге җыелма гариза нигезендә үз гаризаларын формалаштыралар һәм аларны, анализ ясау өчен, вәкаләтле учреждениегә җибәрәләр.

5.1.16.3. Электрон кибеттә җыелма гаризага анализ ясау нәтиҗәләре буенча ачыкланган кимчелекләрне биргән көннән соң килә торган эш көненнән башлап ике эш көненнән дә соңга калмыйча, заказ бирүчеләр җыелма гаризаны һәм уртак сатулар үткәрү турында килешүне имзалыйлар.

5.1.16.4. Имзалаганнан соң вәкаләтле учреждение гаризаны финанс контроле органына җибәрә.

5.1.16.5. Өч эш көне (капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкаруга сатып алу уздыру очрагында – җиде эш көне) узганнан соң, финанс контроле органы тарафыннан сатып алу турындагы гаризаны килештерү статусы буенча мәгълүмат булмаган очракта, заказ бирүче финанс контроле органыннан планлаштырыла торган сатып алуга карата кабул ителгән карар турында мәгълүматны аныклый.

5.1.16.6. Финанс контроле органы тарафыннан сатып алу турында гариза кире кагылган очракта, заказ бирүче, кабат анализ ясау максатыннан, сатып алу үткәрү турында гаризаның төзәтелгән вариантын вәкаләтле органга җибәрә.

5.1.16.7. Уртак сатулар үткәрү турында җыелма гариза формалаштыра торган заказ бирүче вәкаләтле учреждениегә электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә яки кәгазь чыганакта барлык заказ бирүчеләр тарафыннан

имзаланган уртак стаулар турындагы килешүне, башлангыч (максималь) бәяләргә нигезләмәне җибәрә.

5.2. Сатып алу турында мәгълүматлар урнаштыру.

5.2.1. Сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамә урнаштыру.

5.2.1.1. Финанс контроле органы тарафыннан товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә гариза килештерелгәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле учреждение Электрон кибеттә сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамә формалаштыра һәм заказ бирүчегә, раслау өчен, сатып алу турында хәбәрнамә проектын юллый.

5.2.1.2. Хәбәрнамә проекты сатып алулар үткәрү турында гаризаның 2 бүлегендә күрсәтелгән (Регламентка 1 номерлы кушымта) җаваплы вазифаи затка электрон документлар әйләнеше системасында раслауга җибәрелә.

5.2.1.3. Заказ бирүченең җаваплы вазифаи заты сатып алу турында хәбәрнамә проектын алган көннән соң килә торган бер эш көне эчендә, 16.00 сәгатьтән дә соңга калмыйча, хәбәрнамә проектын раслый һәм имзалый.

5.2.1.4. Хәбәрнамә проектын электрон документлар әйләнеше системасында имзалау Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсенең таныклаучы үзәге тарафыннан бирелгән электрон имзаны тикшерү ачкычларының квалификацияле сертификатларын һәм электрон имза чараларын кулланып башкарыла.

5.2.1.5. Хәбәрнамә проекты вакытында имзаланмаган очракта, вәкаләтле учреждение сатып алу үткәрү срокларына үзгәрешләр кертә һәм аны, яңадан раслау өчен, заказ бирүчегә юллый.

5.2.1.6. Заказ бирүче тарафыннан расланган сатып алу турында хәбәрнамә проектын алганнан соң, вәкаләтле учреждение, 44-ФЗ номерлы федераль закон белән билгеләнгән срокларны үтәп, сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәне килештерү өчен финанс контроле органына юллый. Килештергәннән соң, Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру өчен җибәрә. Бердәм мәгълүмат системасының ябык өлешендә хәбәрнамә финанс контроле органы тарафыннан вакытында килештерелмәгән очракта, вәкаләтле учреждение хәбәрнамәгә үзгәреш кертә һәм аны кабат финанс контроле органына килештерүгә һәм урнаштыруга җибәрә, шулай ук (кирәк булган очракта) заказ бирүчегә товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү срокларына үзгәрешләр кертү кирәклеге турында хәбәр итә.

5.2.1.7. Вәкаләтле учреждение сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәне формалаштырганчы сатып алу үткәрү турында гаризага төзәтмәләр кертергә кирәк булган очракта, заказ бирүче сатып алу үткәрү турында гаризага һәм Регламентның 5.1.2.1 пунктында күрсәтелгән исемлек нигезендә сатып алу турында теркәп бирелә торган документларга төзәтмәләр кертә һәм югарыда күрсәтелгән документларның имзаланган вариантларын вәкаләтле учреждениегә җибәрә.5.1.2.1

5.2.1.8. Бердәнбер тәэмин итүчедән 44-ФЗ номерлы федераль законның 93 статьясындагы 12 өлеше белән каралган суммага электрон формада товар сатып алынган очракта, заказ бирүче сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәне һәм документларны 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә формалаштыра һәм Бердәм

мәгълүмат системасында урнаштыра. Алдагы гамәлләр 44-ФЗ номерлы федераль законның 93 статьясындагы 12 өлеше нигезендә заказ бирүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә башкарыла.

5.2.1.9. Сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәгә үзгәрешләр кертү.

5.2.1.10. Сатып алу турында хәбәрнамәгә үзгәрешләр кертү 44-ФЗ номерлы федераль законның 42 статьясындагы 4 өлеше нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.1.11. Сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәгә үзгәрешләр кертү кирәк булган очракта, заказ бирүче вәкаләтле учреждениегә электрон документлар әйләнеше системасы аша, үзгәрешләр кертелә торган барлык документларны теркәп, үзгәрешләр кертү турында хат юллый. Үзгәрешләр Бердәм мәгълүмат системасында сатып алуда катнашуга гаризалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла. Үзгәрешләр кертү турындагы хат вәкаләтле учреждениегә эш көннәрендә 10.00 сәгатькә кадәр җибәрелә.

5.2.2. Тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүне гамәлдән чыгару.

5.2.2.1. Заказ бирүче тарафыннан тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүне гамәлдән чыгару турында карар кабул ителгән очракта, заказ бирүче сатып алуны гамәлдән чыгару турында хатны электрон документлар әйләнеше системасы аша 14.00 сәгатькә кадәр вәкаләтле учреждениегә җибәрә. Хат заказ бирүче җитәкчесе яки вәкаләт бирелгән зат тарафыннан имзаланган булырга тиеш.

5.2.2.2. Тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүне гамәлдән чыгару турында хат алынган көнне вәкаләтле учреждение, Бердәм мәгълүмат системасыннан файдаланып, сатып алуны гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә формалаштыра. Аны финанс контроле органына килештерү өчен юллый. Килештергәннән соң, Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру өчен җибәрә. Сатып алуны гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә Бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган вакыттан алып сатып алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

5.2.3. Сатып алу турында хәбәрнамә нигезләмәләренә аңлатма.

5.2.3.1. Сатып алуда катнашучыдан мөрәҗәгать алынган очракта, вәкаләтле учреждение заказ бирүчегә мәгълүмат хатын һәм килгән мөрәҗәгатьне заказ бирүченең сатып алу үткәрү турындагы гаризасында күрсәтелгән электрон адреска җибәрә.

5.2.3.2. Заказ бирүче мөрәҗәгатькә җавапны мәгълүмат хатында күрсәтелгән вакыт эчендә түбәндәге адрес буенча электрон почтага җибәрә: 2991723@mail.ru. Мөрәҗәгатькә җавап заказ бирүче җитәкчесенең яки моның өчен вәкаләт бирелгән затның мөһере һәм имзасы белән раслана. Җавап сканерланган рәвештә, шулай ук Word форматында җибәрелә.

5.2.3.3. Вәкаләтле учреждение хәбәрнамә нигезләмәләренә аңлатмаларны Бердәм мәгълүмат системасында 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә урнаштыра.

5.3. Конкурентлы процедуралар үткәрү.

5.3.1. Конкурентлы процедуралар 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләре нигезендә үткәрелә.

5.3.2. Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләре белән билгеләнгән тәртиптә һәм вакыт эчендә

гаризаларны карап тикшерә, гаризаларның тиешле таләпләргә туры килү-килмәве яки аларны кире кагу турында карар кабул итә, гаризаларны бәяли, гаризаларга тәртип номерлары бирә һәм сатып алуда катнашучыны җиңүче дип таный.

5.3.3. Конкурентлы процедуралар үткәргәндә Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссиянең функцияләре, вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе Башкарма комитетның 2013 елның 25 ноябрендәге 10204 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру турында»гы карары белән билгеләнгән.

5.4. Контракт төзү.

5.4.1. Электрон процедура нәтиҗәләре буенча контракт төзү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту заказ бирүче тарафыннан 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләре нигезендә мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла.

5.4.2. Сатып алуда катнашучыны контракт төзүдән читләшкән дип тану, сатып алуда катнашучыны контракт төзүдән читләшкән дип тану турындагы беркетмәләрне Бердәм мәгълүмат системасында формалаштыру һәм урнаштыру заказ бирүче тарафыннан 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләре нигезендә мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла.

## VI. Сатып алуларны әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту

6.1. Заказ бирүчеләр 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә сатып алуларның үтәлешенә һәм аларның сатып алуларның план-графикларына туры килү-килмәвенә мониторинг үткәрә, контрактлар реестрына кертү өчен мәгълүматларның 44-ФЗ номерлы федераль закон нормаларына туры килүен тикшерә, шулай ук контрактлар үтәлеше барышын мониторинглауны һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

6.2. Вәкаләтле учреждение тарафыннан сатып алуны әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны мониторинглау сатып алулар буенча даими хисаплар әзерләү һәм анализлау, сатып алу үткәрүгә гаризаларның, конкурентлы процедуралар буенча сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәләрнең, тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү беркетмәләренең 44-ФЗ номерлы федераль закон нормаларына туры килүен тикшерү юлы белән башкарыла.

6.3. Вәкаләтле учреждение мөрәҗәгате буенча заказ бирүчеләр вәкаләтле учреждениегә сатып алулар буенча кирәкле мәгълүматны тапшыра.

6.4. Сатып алуларны әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту нәтиҗәләре заказ бирүчеләр тарафыннан план чорына план-графикларны формалаштырганда һәм агымдагы финанс елына әлеге документларга төзәтмәләр керткәндә кулланыла.

Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу белән идарә итү регламентына
1 номерлы кушымта
(Форма)
**«Казан шәһәренең конкурентлы сәясәт һәм сатып алулар дирекциясе» муниципаль казна учреждениесе директоры Р.М.Мөдәрисовка**

**Товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә гариза***

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Заказ бирүче | Учреждениенең тулы атамасы, почта индексы, почта адресы, урнашу урыны адресы, электрон почта адресы, телефоны күрсәтелә |
| 2 | Җаваплы вазифаи зат | Учреждение җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме ТУЛЫСЫНЧА күрсәтелә.<br>Тел. ______________________.<br>Электрон почта адресы: ___________________________ |
| 3 | Җаваплы башкаручы | Гаризаны формалаштыру өчен җаваплы башкаручының фамилиясе, исеме, атасының исеме ТУЛЫСЫНЧА күрсәтелә.<br>Тел. ______________________.<br>Электрон почта адресы: ___________________________ |
| 4 | Контракт идарәчесе/контракт хезмәтенең җаваплы хезмәткәре турында мәгълүматлар | Контракт идарәчесе яки контракт хезмәтенең җаваплы хезмәткәре (булган очракта) турында мәгълүматлар күрсәтелә.<br>Контракт идарәчесе:<br>контракт идарәчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме ТУЛЫСЫНЧА күрсәтелә.<br>Тел. ______________________.<br>Электрон почта адресы: ___________________________<br><br>Контракт хезмәтенең җаваплы хезмәткәре:<br>фамилиясе, исеме, атасының исеме ТУЛЫСЫНЧА күрсәтелә.<br>Тел. ______________________.<br>Электрон почта адресы: ___________________________ |
| 5 | Тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү ысулы | Тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү ысулы күрсәтелә:<br>– электрон формада ачык конкурс;<br>– электрон формада аукцион;<br>– электрон формада котировкалар сорату;<br>– шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар белән билгеләнгән тәртиптә расланган проект документларын күздә |

*Гариза Word, Excel форматында рәсмиләштерелә; шрифты – туры New Roman Times, үлчәме – 11-12. Астына сызу, курсив кулланылмый.

Документ создан в электронной форме. № 71580-Инф от 20.06.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 21 из 45. Страница создана: 20.06.2025 15:09
ЕМСЭД

| | | |
|---|---|---|
